МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.11.2024 Казан ш. № 652-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 21.06.2022 № 380-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Җир мөнәсәбәтләрен көйли торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә боерам:

1. «Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 21.06.2022 № 380-пр боерыгы белән (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.09.2022 № 534-пр, 11.04.2024 № 207-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертергә тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
07.11.2024 № 652-пр
боерыгы белән расланган

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 21.06.2022 № 380-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) сату-алу шартнамәсе проекты, җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсе проекты, шулай ук, күрсәтелгән шартнамәләрне имза кую өчен гариза бирүчегә юллау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген милек итеп бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).»;

2.3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.5. Әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүче кәгазь сыйфатында Министрлыктан шәхсән үзе алырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7, 2.3.8 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе (җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсе) реквизитлары:

Шартнамә төзергә вәкаләтле орган атамасы;

шартнамәгә имза куярга вәкаләтле зат вазыйфасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасы исеме (соңгысы - булса);

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасы исеме (соңгысы - булса); (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме һәм атасы исеме (соңгысы - булса).

2.3.7. Реестр язуы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тормый.

2.3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе нинди дә булса Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасында теркәлми.»;

2.4.1 пунктта «17 көн эчендә» сүзләрен «15 көн эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

2.4.2 пунктта «17 көн эчендә» сүзләрен «15 көн эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

2.4.3 пунктта «17 көн эчендә» сүзләрен «15 көн эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4, 2.4.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ гариза бирүчегә Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә көндә тапшырыла.»;

2.6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

Күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә җир кишәрлеген милек итеп яки арендага бирү өчен гариза бирүче гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1. Гариза бирүченең җир кишәрлеген милеккә, арендага алу хокукын раслаган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең башкарма комитеты вәкаләтле федераль органы билгеләгән исемлектә каралган документлар, Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар (Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегенең 6, 13 пунктлары) искәрмә булып тора

2. Физик зат яки шәхси эшкуар булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) яисә физик яки юридик затның, шәхси эшкуар вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

3. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү турында гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ;

4. Гариза бирүче чит ил юридик заты булса, юридик затның чит дәүләтнең законнарына туры китереп дәүләт теркәве узуы турындагы документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе;

5. Гариза бирүченең бинага, корылмага яисә бүлмәгә булган хокуклары Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса (алга таба - ЕГРН), аның бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе;

6. Гариза бирүченең соралган җир кишәрлегенә хокуклары ЕГРНда теркәлмәгән булса, аның җир кишәрлегенә булган хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе (җир кишәрлегенә андый хокуклар булса);

7. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) соралган җир кишәрлегендә урнашкан үзенең хокукы булган бөтен биналар, корылмаларның, кадастр номерлары (шартлы, инвентарь) һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән исемлеге кертелгән белдерүе.»;

2.6.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«6. Росреестрның № П/0321 боерыгы белән расланган документлар исемлегенең 6, 31 пунктлары белән каралган башка документлар һәм белешмәләрне дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге»;

түбәндәге эчтәлекле 2.7.1, 2.7.2 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.7.1. Гаризаны һәм аларга беркетелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә кермәгән зат мөрәҗәгать иткән;

2) гаризада һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартулар, өстәп язулар һәм төзәтүләр булу.

2.7.2. Гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{17}$ статьясының 1 пункты нигезләмәләренә туры килми (алга таба – РФ ҖК);

2) документлар тиеш булмаган органга тапшырылган;

3) әлеге Регламентның 2.6.2 пункты нигезендә гариза бирүче шәхсән үзе тапшырылырга тиешле документларның тапшырылмавы.»;

3 бүлектә:

абзац четвертый пункта 3.4.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.6.2 пунктта «Бердәм портал,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә.

Гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер бирелү һәм “Документларны тикшерү” статусы турында электрон хәбәр Республика порталындагы шәхси кабинетта автомат рәвештә чагыла.»

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көченн югалткан дип танырга;

3.6.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.3. Бүлек белгече Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирү Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Бүлек белгече карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта);

электрон эшләрне, шул исәптән, гариза бирүче беркеткән электрон формаларын һәм документларның электрон образларын карап чыга, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта гариза бирүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кабул итүдән баш тарту турында баш тарту сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Бүлек белгече документларны кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта гариза бирелгәннән ун көннән дә соңга калмыйча гариза бирүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карамыйча кайтару турында кайтару сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Бүлек белгече документлар кабул ителгән көнне “Ведомствоара мәгълүмати арадашлык” административ процедурасын башкарырга керешә.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки сәбәпләре күрсәтелеп гариза бирүчегә кайтарылган гариза һәм аңа беркетелгән документлар комплекты.»;

3.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Министрлыкка документлар формасында гариза бирүчедән кергән документлар комплектын карап чыгу

Контроль бүлеге белгече Бүлек белгече катнашында кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшереп чыга.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, Бүлек белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияләмичә һәм Бүлек белгече әзерләгән аңлатма буенча телдән генә документларны кабул итүдән баш тарту өчен (гаризаны һәм аңа беркетелгән документларын кире кайтару нигезләре) ачыкланган сәбәпләрне аңлатып гариза бирүчегә кайтара.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен тапшырган очракта, Бүлек белгече оригиналга карап документларның күчермәләрен чагыштыра һәм үз имзасы белән раслый.

Әлеге регламентның 3.6.3 пункты билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр турында телдән аңлату, гариза бирүчегә кайтарылган гариза һәм аңа беркетелгән документлар.»;

3.6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.4. Документлар Министрлыкка почта аша документлар формасында кергән очракта контроль бүлеге хезмәткәре Бүлек белгече катнашында кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшереп чыга.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Контроль бүлеге белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Бүлек белгече кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гариза кабул ителгән көнне гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кабул итүдән баш тартып һәм баш тарту сәбәпләрен аңлатып белдерү юллый.

Бүлек белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гариза бирелгәннән ун көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карамыйча кайтару турында кайтару сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән яки сәбәпләре күрсәтелеп гариза бирүчегә кайтарылган документлар комплекты.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга (оешмаларга) юллау »;

Түбәндәге эчтәлекле 3.7.2.1, 3.7.2.2, 3.7.2.3, 3.7.2.4 пунктлар белән тулыландырырга:

«3.7.2.1. Җир кишәрлеге бирү өчен кирәк булган соралган документлар исемлеге:

1) соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос Татарстан Республикасы буенча Теркәү кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә юллана.

2) күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар һәм (яки) корылмалар турында) ЕГРНнан өземтә. Запрос Татарстан Республикасы буенча Теркәү кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә юллана.

3) күчемсез милек объекты турында (бүлмәнең милек хуҗасы мөрәҗәгать иткән очракта, соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар һәм (яки) корылмалардагы бүлмә турында) ЕГРНнан өземтә. Запрос Татарстан Республикасы буенча Теркәү кадастр һәм картография федераль хезмәте

идарәсенә юллана.

4) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән);

5) шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә. Запрос Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә юллана;

6) Росреестрның № П/0321 боерыгы белән расланган документлар исемлегенең 6, 31 пунктлары белән каралган башка документлар һәм белешмәләр. Запрос дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына юллана.

3.7.2.2. Ведомствоара мәгълүмати запрослар әлеге Регламентның 3.7.2.1 пункты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан күрсәтелгән органнарга юллана.

Әлеге Регламентның 3.7.2.1 пункты белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.7.2.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.

3.7.2.4. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин булмаса;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның 7$^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомоствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе).

Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган соралган документлар (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәр.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.7.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләгәндә сату-алу шартнамәсе проектлары, җир кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе әзерләнә, шулай ук, күрсәтелгән шартнамә проектларын имза кую өчен гариза бирүчгә юллана, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турында карар проекты яисә арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты) (алга таба – баш тарту турында карар проекты) әзерләнә.»;

3.9.3 пунктта:

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.4 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.5 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.6 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.7 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.7. Хокук идарәсе белгече арендага бирү (сату-алу) шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый, килештерә һәм хокук идарәсе башлыгына арендага бирү (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын – килештерү өчен яисә арендага бирү (сату-алу) шартнамәсе проектында яки баш тарту турында карар проектында кисәтүләр булган очракта хокук идарәсе бәяләмәсе проектын имзалау өчен юллый.»;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты әзерләү һәм (яки)” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.8 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.9 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.10 пунктның өченче абзацында «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.11 пунктта:

беренче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «арендага (милеккә) бирү турында карар проекты” сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.12. Министрның беренче урынбасары арендага бирү шартнамәсе проектына һәм кушып җибәрелә торган хатка, яисә һәм кушып җибәрелә торган хат белән баш тарту турында карар проектына кул куя һәм регистрацияләү өчен контроль бүлегенә юллый яисә сату-алу шартнамәсе проекты һәм кушып җибәрелә торган хат килештерелә дә имза куярга минстрга юллана.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада алыну күрсәтелгән икән, министрның беренче урынбасары арендага бирү шартнамәсе проектына һәм кушып җибәрелә торган хатка электрон документ формасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары имзалаган һәм регистрацияләү өчен контроль бүлегенә юлланган арендага бирү шартнамәсе, яисә баш тарту турында карар проекты яки килештерелгән һәм имза кую өчен министрга юлланган сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.9.13, 3.9.14 пунктлар белән тулыландырырга:

«3.9.13. Министр сату-алу шартнамәсе проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хатны имзалый һәм регистрацияләү өчен контроль бүлегенә юллый.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада алыну күрсәтелгән икән, министр стау-алу шартнамәсе проектына һәм кушып җибәрелә торган хатка электрон документ формасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министр имзалаган һәм регистрацияләү өчен контроль бүлегенә юлланган сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат.

3.9.14. Әлеге Регламентның 3.9.3 – 3.9.14 пунктларында күрсәтелгән аерым процедуралар техник мөмкинлекләр булганда дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системаны кулланып, автомат режимда башкарыла.»;

3.10.2 пунктның беренче абзацында «арендага (милеккә) бирү турында карар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.10.5 пунктның җиденче абзацында «арендага (милеккә) бирү турында карар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 3 нче кушымтада:

8 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплексны үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплексны үсеш турында карар кабул ителсә; җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән шушы җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе яки әлеге җир

кишәрлегенә хокукы булган зат  мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;»;

9 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса, яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә, яки җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган булса, әлеге җир кишәрлегенең федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булып, шул җир кишәрлеген бирү турында күрсәтелгән объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;»;

10 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган, яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә, һәм территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса, җир кишәрлеген арендага бирү турында территорияне комплекслы үзләштерү буенча шартнамә төзелгән яки әлеге объектларны төзү бурычы куелып, территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;»;

13 подпунктта «үз ихтыяҗы өчен» сүзләреннән соң «яки крестьян (фермер) хуҗалыгы буенча эшчәнлек итү өчен» сүзләрен төшереп калдырырга.

түбәндәге эчтәлекле 28, 29 подпунктлар белән тулыландырырга:

«28) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы җирләреннән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге (алга таба – гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге), яисә гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген дә исәпләп, бирелгән җир кишәрлекләренең мәйданы крестьян (фермер) эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән җир кишәрлекләре мәйданына туры килми;

29) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге алдарак кергән җир кишәрлеген бирү турында гариза буенча дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы

җирләреннән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен бирелгән.»;

җир кишәрлеген бирү турында

түбәндәге эчтәлекле 5 нче кушымта белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

_________________________________________
(юридик зат атамасы)

_______________________________________
(физик затның фамилиясе, инициаллары)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

_________________________________ № ________ регистрацияләнгән гариза нигезендә: ________________________________ нигезләр буенча хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Баш тарту сәбәбенә аңлатма: ______________________________________.
Өстәмә хәбәр итәбез: _____________________________________.
(дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәбен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат күрсәтелә, булса, башка өстәмә мәгълүмат бирелә)

Сез күрсәтелгән кимчелекләр бетерелгәннән соң хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән Министрлыкка кабат мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тарту Министрлыкка судка кадәр тәртиптә шикаять ителә ала, шулай ук, суд тәртибендә дә.

___________________________
(вазыйфа, Ф.И.ӘИ. (соңгысы - булса)».